**КАРАР**

**25 ноябрь, 2024 ел** **№2**

# Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлеге Үрәсбаш авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 25 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез 2025 елда Кукмара муниципаль районының Түбән Үрәс авыл җирлеге Үрәсбаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан; 1 төркем инвалидларыннан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә срокль хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация белән хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 2000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Үрәсбаш авылының Октябрь урамындагы вак таш һәм асфальт түшәлгән юлларны төзү, ремонтлау һәм төзекләндерү, вак таш сатып алу, проект-смета документациясе һәм технадзорны гамәлгә ашыру, Үрәсбаш авылының урам юл челтәрен карап тоту, ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу, урнаштыру, юлларны төзекләндерү, карап тоту һәм төзекләндерү буенча башка төр эшләр; җәй көне юлларны кардан чистарту һәм территорияләрне чабу; (ягулык-майлау материаллары сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү);
- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын гидрантын сатып алу һәм урнаштыру, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү; проект-смета документациясе);
- урамнарны яктырту җайланмасы (энергияне саклый торган лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу һәм урнаштыру, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү);
- янгын гидрантын сатып алу һәм урнаштыру (материаллар сатып алу һәм урнаштыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү; проект-смета документациясе);
- торак пункт территориясен төзекләндерү (Үрәсбаш территориясен төзекләндерү, агачларны һәм куакларны кисү һәм йоклату, килешү буенча эш өчен түләү, территорияне төзекләндерү буенча башка төр эшләр)

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 204 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 136 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 136 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Үрәс авыл җирлегенең Үрәсбаш авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип таныргa.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «Сез 2025 елда Кукмара муниципаль районының Түбән Үрәс авыл җирлеге Үрәсбаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан; 1 төркем инвалидларыннан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация белән хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала,2000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Үрәсбаш авылының Октябрь урамындагы вак таш һәм асфальт түшәлгән юлларны төзү, ремонтлау һәм төзекләндерү, вак таш сатып алу, проект-смета документациясе һәм технадзорны гамәлгә ашыру, Үрәсбаш авылының урам юл челтәрен карап тоту, ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу, урнаштыру, юлларны төзекләндерү, карап тоту һәм төзекләндерү буенча башка төр эшләр; җәй көне юлларны кардан чистарту һәм территорияләрне чабу; (ягулык-майлау материаллары сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү);

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын гидрантын сатып алу һәм урнаштыру, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү; проект-смета документациясе);

- урамнарны яктырту җайланмасы (энергияне саклый торган лампалар, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу һәм урнаштыру, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү);

- янгын гидрантын сатып алу һәм урнаштыру (материаллар сатып алу һәм урнаштыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү; проект-смета документациясе);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (Үрәсбаш территориясен төзекләндерү, агачларны һәм куакларны кисү һәм йоклату, килешү буенча эш өчен түләү, территорияне төзекләндерү буенча башка төр эшләр)

«РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип исәпләргә.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәсен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ruадресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Түбән Үрәс авыл җирлеге башлыгы: В.Г. Сәфәров